**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**25.04. 2022** **№ 110**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2018 елның 13 июлендәге 158 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Нурлат муниципаль районы Советының 2018 елның 13 июлендәге 158 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.

Комиссия комиссия рәисеннән, комиссия рәисе урынбасарыннан, секретарь һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара».

1.2. Нигезләмәнең 3.21 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.21. Комиссия административ хокук бозу билгеләрен яисә җинаять составын үз эченә алган муниципаль хезмәткәр тарафыннан гамәл кылу факты (гамәл кылмау факты) ачыкланган очракта, комиссия рәисе күрсәтелгән гамәлне (гамәл кылмау) кылу турында мәгълүматны һәм мондый фактны хокук саклау органнарына өч көн эчендә тапшырырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Советының законлылыкны һәм хокук тәртибен үтәү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин